| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>РУКОВОДИТЕЛЬ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА<br>ГОРОДА АЗНАКАЕВО<br>АЗНАКАЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>ЖИТӘКЧЕСЕ |

ул. Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330 Ленин ур., 14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330

Тел. факс (885592) 7-15-50, 7-00-37, E-mail: aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**12.04.2019 ел** **№ 11**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2013 елның 27 сентябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентына үзгәреш кертү турында (19.03.2014 № 10, 20.08.2014 № 31, 04.06.2018 № 12 карарлар редакциясендә)

«Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп төзүне һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны җайга салучы нормаларны тәртипкә салу өлешендә Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 29 декабрендәге 558-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, Азнакай шәһәр прокуратурасы протесты нигезендә, 28.02.2016 ел, № 02-08-02/205-2019 карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2013 елның 27 сентябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентына (19.03.2014 № 10, 20.08.2014 № 31, 04.06.2018 № 12 карарлар редакциясендә) 2.4.2 пунктының 2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле «г» пунктын өстәргә:

"г) күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп төзүне гамәлгә ашыру тәртибе таләпләрен бозу.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче М.И.Солтанов